Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

2 февраль, 2024 ел                                                                                № 7

Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Күм һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «2021 елд түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасынд җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралар хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарлары нигезендә Татарста Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлег башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүне гарантияләнгән исемлегенең кушымта итеп бирелгән бәясен расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкин авыл җирлегендә «Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнг исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2023 елны 31 гыйнварының 4 номерлы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитет карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан көченә керә.

4. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарст Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында һәм мәгълүм стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы                                  А.Р.Сәйфетдинов

Кушымта № 1
Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланды
2 февраль, 2024 ел, № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Мәет җирләү өчен табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2347,43 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 541,74 |
| 4. | Кабер казу һәм күмү | 5481,03 |
| | **Барлыгы** | **8370,20** |

Кушымта № 2
Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланды
2 февраль, 2024 ел, № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **№ п/п** | **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Мәетне кәфенләү өчен | 436,35 |
| 3. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1911,08 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 541,74 |
| 5. | Кабер казу һәм күмү | 5481,03 |
| | **Барлыгы** | **8370,20** |